**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**12 ноябрь 2022 ел** **№ 3**

**«Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 22 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Кәркәүч авылы, Ленин урамы, 104 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 22 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Кәркәүч авылы, Ленин урамы, 102 нче йорт адресы буенча урнашкан контора бинасында үткәрергә.

3. 2022 елның 23 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Кәркәүч авылы, Ленин урамы, 104 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. 2022 елның 23 ноябренә 12 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Кәркәүч авылы, Ленин урамы, 39 нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:
- М. Җәлил, Яшел һәм Яшьләр урамнары буенча юлга вак таш җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Кәркәүч авылындагы урамнарны яктыртуның энергияне сак тотучы лампаларын сатып алу һәм урнаштыру;
- Кәркәүч авылында чишмә ремонтлау, проект-смета документларын эшләү;
- Кәркәүч авылындагы юлларны кардан чистарту; түләү килешенү буенча.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

7. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Кәркәүч авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы М.Ф.Зәйнетдинов